БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 02 2021 ел № 62

«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына (2019 елның 25 декабрендәге 386 номерлы үзгәреләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән (2019 елның 25 декабрендәге 386 номерлы үзгәреләр белән) расланган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә (алга таба – Тәртип) 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 12 абзацы белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка төрле түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов